**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 октябрендәге 4506 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 15 декабрендәге 3309 номерлы**
**«Совет районының Сеченов урамындагы җир кишәрлекләре**
**өлешләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы һәм**
**2021 елның 5 августындагы 1943 номерлы**
**«Казан шәһәре Вахитов районының Галиәсгар Камал урамындагы**
**җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы**
**карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга туры китереп, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте гаризасы нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 15 декабрендәге 3309 номерлы «Совет районының Сеченов урамындагы җир кишәрлекләре өлешләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы һәм 2021 елның 5 августындагы 1943 номерлы «Казан шәһәре Вахитов районының Галиәсгар Камал урамындагы җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарларын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**